**III ЧАКЫРЫЛЫШ**
**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БӨГЕЛМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**«ПЕТРОВКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**
**XXXXVI СЕССИЯ**

**КАРАР № 5**

Петровка авылы «20» май 2019г

**Петровка авыл җирлеге Советының**
**2019 елның 14 февралендә булып узган**
**XXXXV сессиясендә кабул ителгән**
**“Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы**
**“Петровка авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә**
**гавами тыңлаулар (җәмәгать тикшерүе)**
**оештыру һәм үткәрү тәртибе турында”гы**
**Нигезләмәне раслау хакында”гы 5нче карарга**
**үзгәрешләр кертү турында**

2003 елның 6 октябрендә кабул ителгән «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы №131-ФЗ законга үзгәрешләр кертелүгә бәйле рәвештә һәм Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының «Петровка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып,

**Петровка авыл җирлеге Советы**
**КАРАР БИРДЕ:**

Петровка авыл җирлеге Советының 2019 елның 14 февралендә булып узган XXXXV сессиясендә кабул ителгән “Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы “Петровка авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә гавами тыңлаулар (җәмәгать тикшерүе) оештыру һәм үткәрү тәртибе турында”гы Нигезләмәне раслау хакында”гы 5нче карарга түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1. 4нче бүлектә:

*- 4нче пунктны яңа басмада бәян итәргә:*

«4. Гавами тыңлаулар халык, Бөгелмә муниципаль районы Петровка авыл җирлеге Советы, Бөгелмә муниципаль районы “Петровка авыл җирлеге”

муниципаль берәмлеге башлыгы (“Петровка авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге башкарма комитеты җитәкчесе) инициативасы буенча уздырыла.

Халык, Бөгелмә муниципаль районы Петровка авыл җирлеге Советы инициативасы буенча үткәрелә торган гавами тыңлаулар Петровка авыл җирлеге Советы тарафыннан билгеләнә, ә “Петровка авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге башлыгы (“Петровка авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге башкарма комитеты җитәкчесе) инициативасы буенча уздырыла торганы “Петровка авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге башлыгы тарафыннан билгеләнә.

2. Әлеге карарны җирлек территориясендәге мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә һәм «Интернет» челтәрендә – Бөгелмә муниципаль районының рәсми порталында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешенә контрольлек итүне үз өстемдә калдырам.

**«Петровка авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлеге башлыгы** **Р.Ф. Ибраһимов.**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БӨГЕЛМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ПЕТРОВКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ ИНН 1619003161 СОВЕТ ПЕТРОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БУГУЛЬМИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН